ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 275

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«23» июль 2018 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актларын Россия Федерациясе Торак кодексына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 09 апрелендәге 137 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта «коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану буенча билгеләнгән норматив күләменең нигезле булу-булмавы,» сүзләреннән соң «күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннарның милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләменең нигезле булу-булмавы һәм мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик дәрәҗә индекслары саклануы,» сүзләрен өстәргә;

3 бүлекнең 1 нче таблицасында:

9 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Күпфатирлы йорт белән | КФЙ белән идарә итү гражданнарның яшәеше өчен | РФ ТК 161 ст.; РФ | - » |

| | | | |
|---|---|---|---|
| идарә итү | иминлекле һәм куркынычсыз шартлар тудыруны, КФЙ уртак мөлкәтнең тиешенчә карап тотылуын, аталган мөлкәттән файдалану мәсьәләләрен хәл итүне, шулай ук мондый йортларда яшәүче гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне яки, РФ ТК 157.2 статьясында каралган очракларда, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәте составына керә торган инженер коммуникацияләренең һәм башка төрле җайланмаларның хезмәтләр күрсәтүгә даими рәвештә әзер булып торуын тәэмин итәргә тиеш (алга таба – инженер системаларының әзерлеген тәэмин итү). Россия Федерациясе Хөкүмәте КФЙ белән идарә итү эшчәнлегенең стандартларын һәм кагыйдәләрен билгели | Хөкүмәтенең 416 номерлы карары белән расланган Тәртип | |

13 нче юлны төшереп калдырырга;

15 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Күпфатирлы йортларда һәм торак йорт-ларда милекче-ләргә һәм биналардан файдалану-чыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү | Кулланучыга коммуналь хезмәтләр күрсәтү һәм аларның коммуналь хезмәтләр сыйфатына карата таләпләргә җавап бирүе.<br><br>РФ ТК 157.2 статьясында каралган очракта күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте яки торак кооперативы яисә башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә түбәндәгеләрне бурычлы:<br>1) ресурс белән тәэмин итүче оешмаларга, каты коммуналь калдык-лар белән эш итүче региональ оператор-га коммуналь хезмәтләргә түләү хисаплау өчен кирәкле, шул исәптән күпфатирлы йортта урнаштырылган хосусый исәпкә алу җиһазлары | РФ ТК 157.2 ст.;<br>РФ ТК 161 ст. 11 өл.<br>РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр | -» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (мондый күрсәткечләр күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре һәм социаль найм шартнамәләре яки дәүләти яисә муниципаль торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча әлеге йортта торак урыннарны наймга алучылар тарафыннан идарәче оешмага, торак милекчеләре тарафыннан ширкәтенә яки торак кооперативына яисә башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативына тапшырылганда) һәм күмәк (йорттагы гомуми) исәпкә алу җиһазлары күрсәткечләре турында мәгълүмат бирергә;<br>2) коммуналь ресурсларның сыйфатына һәм аларны күпфатирлы йортта уртак мөлкәт чикләренә кадәр тапшыруның өзлексезлегенә контрольне гамәлгә ашырырга;<br>3) күпфатирлы йортта биналарның милекчеләреннән һәм социаль найм шартнамәләре яки дәүләти яисә муниципаль торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча әлеге йортта торак урыннарны наймга алучылардан коммуналь хезмәтләрнең сыйфатына  һәм (яки) мондый хезмәтләр белән тәэмин итүнең өзлексезлегенә карата таләпләрнең бозылуы, коммуналь хезмәтләр өчен түләү хисаплаганда җибәрелгән хаталар турында мөрәҗәгатьләрне кабул итәргә һәм аталган мөрәҗәгатьләрне караганда, аларда бәян ителгән фактларга тикшерүләр уздырганда, ачыкланган бозуларны бетергәндә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат җибәргәндә ресурс белән тәэмин итүче оешмалар һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итүче региональ оператор белән хезмәттәшлек итәргә;<br>4) ресурс белән тәэмин итүче оешмаларга күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренә һәм | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | социаль найм шартнамәләре яки дәүләти яисә муниципаль торак фонды торак урыннарының найм шартнамә-ләре буенча әлеге йортта торак урыннарны наймга алучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору яки чикләү өчен күпфатирлы йортта уртак мөлкәткә үтеп керүне тәэмин итәргә яисә, ресурс белән тәэмин итүче оешмалар белән килешенеп, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренә һәм социаль найм шартнамәләре яки дәүләти яисә муниципаль торак фонды торак урыннарының найм шартнамәләре буенча әлеге йортта торак урыннарны наймга алучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтелүне туктатып торуны яки чикләүне гамәлгә ашырырга | | |

23 нче юлда «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 15 мартындагы 195 номерлы карары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 30 мартындагы 195 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

5.66 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Юридик затка, шәхси эшкуарга үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында билгеләнгән срокта бозуларны бетерү турында күрсәтмә таләпләрен үтәү мөмкин булмаган очракта, күрсәтмә бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар күрсәтмәне үтәү срогы тәмамланырга кимендә биш эш көненнән соңга калмыйча Инспекциягә бозуны бетерү һәм күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында гозер белән үтенеч язуын җибәрәләр. Үтенеч язуына юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан билгеләнгән срокта бозуларны бетерү өчен чараларның тулысынча күрелүен раслаучы документлар теркәлә.

Үтенеч язуын канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) карарны Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) үтенеч язуы Инспекциядә теркәлгән көннән соң өч эш көненнән артмаган срокта кабул итә. Үтенеч язуын канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар нигезле булырга тиеш. Әгәр күрсәтмәдә билгеләнгән срокта бозу очрагын бетерү мөмкин булмаса, ләкин күрсәтмә бирелгән юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ачыкланган бозуны бетерү өчен кирәкле, аларга бәйле булган барлык чаралар күрелмәсә, күрсәтмәне үтәү срогын озынайтудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Үтенеч язуын канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта Инспекциянең күрсәтмәне биргән вазыйфаи заты күрсәтмәне үтәү вакытын

озынайту турында хәбәрләмә (әлеге Регламентка 15 нче кушымта) төзи һәм аны имза кую өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) юллый.

Үтәү вакыты: күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында гозерне үз эченә алган язмача үтенеч язуы теркәлгән көннән башлап өч эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында хәбәрләмә яки күрсәтмәне үтәү срогын озынайтудан баш тарту турында язмача җавап.

Күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында хәбәрләмә алганда юридик зат, шәхси эшкуар күрсәтмәнең төп нөсхәсен өч эш көне эчендә аңа тиешле язу кертү өчен Инспекциягә тапшыра.

Күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында язу Инспекциянең күрсәтмәне биргән вазыйфаи заты тарафыннан күрсәтмәнең ике (юридик зат, шәхси эшкуар тапшырган нөсхәгә һәм Инспекция эшендә саклана торган нөсхәгә) нөсхәсенә дә кертелә һәм Инспекциянең күрсәтмәне биргән вазыйфаи затының имзасы белән таныклана. Язу кертелгәннән соң күрсәтмә нөсхәсен кулга алганда юридик затның, шәхси эшкуарның вәкиле аның белән танышып чыгу турында кул куя.

Күрсәтелгән карарның билгеләнгән срокларда үтәлешенә контроль әлеге Регламентта каралган тәртиптә уздырылган планнан тыш тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 15 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 15 нче кушымта

**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ**
**Татарстан Республикасы**
**З.Кызыл ур., 15/9, Казан ш., 420111**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ**
**Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111**

**тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru**

Күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында
ХӘБӘРЛӘМӘ

«__» ________ 20__ ел                                                  № ___________

АДРЕС: ______________________________________________
КЕМГӘ: ______________________________________________
(оешма җитәкчесенең вазыйфасы, Ф.И.А.; физик затның (гражданинның, ШЭ,

вазыйфаи затның вазыйфасын күрсәтеп) Ф.И.А.)

___

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе Сезгә 20___ елның «___» __________ керү № ____ мөрәҗәгатегезне карау нәтиҗәләре буенча күрсәтмәне үтәү срогын озынайту турында 20 __ «___»_________ № _____ карар кабул ителүе хакында хәбәр итә, шуңа бәйле рәвештә Сезгә яки Сезнең тиешенчә рәсмиләштерелгән ышанычнамәсе булган вәкилегезгә, срокны озынайту турында язу кертү өчен күрсәтмәнең төп нөсхәсе белән, 20 ___ елның «___» ________________ ___ сәгатьтә түбәндәге адрес буенча килергә кирәк: ___________________________________________

___________________________________________________________________________________.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы (башлык урынбасары)

______________ ___________________________
(имза) (Ф.И.А.)

Хәбәрләмәнең күчермәсе җибәрелде (тапшырылды): ____________________________________.».

2. Юридик бүлек башлыгына (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны башлык урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С. Саттаровка йөкләргә.

Башлык С.А. Крайнов